ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2022 г. Казань № Пр-1156/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,

мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын үтәү йөзеннән б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Вазыйфаи бурычларны үтәү түбәндәгеләрне күздә тоткан вазыйфалар Вазыйфалар исемлегенә кертелә дип билгеләргә:

хакимият вәкиле функцияләрен яисә оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык функцияләрен даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашыру;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәте күрсәтү;

контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру;

дәүләт сатып алуларын гамәлгә ашыру.

3. Финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлегенә:

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә аларны эштән куганда «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләре, бурычлары һәм җаваплылыклары турында аңлатырга;

әлеге боерыкны Дәүләт комитетының Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

4. Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 18 декабрендәге 489 номерлы боерыгын

гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә әлеге боерыкны Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2022 елның
«__» ______ _________
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге P51

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның иң югары төркемендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның төп төркемендәге вазыйфалары:

эшләр идарәчесе;

бүлек башлыгы.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

бүлек башлыгы урынбасары, сектор мөдире.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

ярдәмче.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

контроль-ревизия бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

технологик тоташтыру өчен түләүне көйләү һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

сәнәгать булмаган өлкә тарифларын җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

технологик аудит бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

инвестиция программалары бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

электр энергиясенә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге: әйдәп баручы консультант;

юридик бүлек: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге: әйдәп баручы белгеч;

оешмалар белән эшләү секторы: әйдәп баручы белгеч;

сәнәгать өлкәсе тарифларын җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: әйдәп баручы белгеч.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның өлкән төркемендәге вазыйфалары:

җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: 1 разрядлы өлкән белгеч.

8. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның кече төркемендәге вазыйфалары:

су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге: 1 разрядлы белгеч.